Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының кырыгынчы утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

6 март, 2024 ел № 305

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Питрәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы нигезендә, гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм «Питрәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2021 елның 8 июлендәге 86 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Питрәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең (алга таба - Кагыйдәләр) җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (Советның 2022 елның 30 мартындагы 147 номерлы, 2022 елның 8 декабрендәге 202, 2023 елның 31 августындагы 256 номерлы, 2023 елның 23 ноябрендәге 274 номерлы карарларына үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. График материалларның эчтәлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- кушымта нигезендә V класслы куркынычның (П4) җитештерү һәм склад объектларының территориаль зоналары чикләрен (16:33-7.271 реестр номеры) үзгәртергә;

- аз катлы торак төзелешенең (Ж2) территориаль зонасы чикләрен 2-3 (16:33-7.108 реестр номеры) кушымта нигезендә үзгәртергә.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетына Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Питрәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карарны ерриториаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында (https://fgistp.economy.gov.ru/) урнаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов